| УКАЗ<br>РАИСА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>РӘИСЕ<br>УКАЗЫ |
|---|---|---|

**«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең аерым территорияләрендә хайваннар котыру авырулы булганга, аларның имин булмавы сәбәпле кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерү турында**

Котыру чиренә бирешүчән соңгы авыру хайванның үләксәсе юкка чыгарылган көннән 60 календарь көн узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Төньяк киңлекнең 55,215395° һәм көнчыгыш озынлыкның 51,397874° географик координатларыннан 10 м радиуста урнашкан «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Әдәмсә авыл җирлегендәге территориядә һәм «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Әдәмсә һәм Зирекле авыл җирлекләрендәге эпизоотия чыганагы чикләреннән 3 км радиустагы территориядә хайваннар котыру авырулы булганга, аларның имин булмавы сәбәпле кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерергә.

2. Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең аерым территорияләрендә хайваннар котыру авырулы булганга, аларның имин булмавы сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында» 2025 елның 9 июлендәге 527 номерлы Указы үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ · АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2025 ел, 17 сентябрь
№ 740